Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге
Нөнәгәр авылы торак пункты

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

от «25» март 2024 ел № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Нөнәгәр авылы торак пункты халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге составына керүче Нөнәгәр авылы гражданнар җыенының 27.10.203 елгы 2енче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларны үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ненәгәр авылы Мәктәп урамы буенча юл-урам челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон капламын норматив хәлгә китерү; Нөнәгәр авылының торак пункты эчендәге юлларны ремонтлау”.

2. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе : И.Н.Закиров